# НОВЫЕ КНИГИ, РЕЦЕНЗИИ

УДК 929(297.1)
https://doi.org/10.22378/2410-0765.2025-15-2.145-149

## Китапка бәяләмә: Гәрәева-Акчура А. Төркиядә табылган татар эзләре: публицистик мәкаләләр, эсселар, тәрҗемәләр (Конья, 2024)

***А.Г. Хәйретдинов***

*ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*

Әлеге бәяләмә Төркиядә басылган һәм XX гасырда бу илгә күченеп киткән татар мөһаҗирләренең тормыш юлларына һәм иҗтимагый эшчәнлегенә багышланган яңа китапның эчтәлеге һәм фәнни әһәмияте белән таныштыра. Басманың фәнни кыйммәте авторның исемнәре татар тарих язмасында аз билгеле булган татарларның биографияләрен яңа табышлар белән тулыландыруыннан гыйбарәт. Моннан тыш, автор Төркия вакытлы матбугатында татарлар турында басылган мәкаләләр белән таныштыра.

**Ачкыч сүзләр:** Төркиядә татарлар, татар мөһаҗирлеге, төрек вакытлы матбугаты татарлар турында, татар публицистикасы, биографияләр


2024 елда Төркиянең Конья шәһәрендә «Atlas Akademi» нәшриятында якташыбыз журналист Айзирәк Гәрәева-Акчураның «Төркиядә табылган татар эзләре: публицистик мәкаләләр, эсселар, тәрҗемәләр» исемле китабы дөнья күрде.

Татар мөһаҗирләренең язмышлары белән кызыксынучы, аларның Төркия үсешенә, бу илнең иҗтимагый яшәешенә, мәдәниятенә, фәненә, мәгарифенә керткән өлешләре белән кызыксынучы кеше буларак та, галим буларак та мин бу китапны игътибарымнан читтә калдыра алмыйм. Бу йөздән аның турында кыска гына бер бәяләмә, ягъни рецензия язып, әлеге хезмәт турында хәбәрне татар җәмәгатьчелегенә җиткерергә телим, хәтта бурычым дип саныйм.

Әлеге китапны миңа Айзирәк ханым үз куллары белән бүләк итте. Айзирәк ханым белән күрешеп танышу миңа Мөхлисә Бубыйның 155 еллыгына багышланган конференциядә насыйп булды. Әлеге фәнни чара

© Хайрутдинов А.Г., 2025

2024 елның 27 ноябрендә Иж-Бубый авылында (Татарстан Республикасы Әгерҗе районы) үткәрелде.




Безгә танышу гына аз булыр иде, аралашып китүебез дә табигый, чөнки язмыш безнең тарихка, шәхесләребезгә караган тикшеренүләребезнең юлларын кисештерде: көннәрдән бер көндә икебез дә Бубыйлар нәселенең татар милли хәтереннән өзелеп югалып калган, онытылган вәкиләсе Мәрьям ханым Бубый (Нигъмәтуллина) Атмаҗаның катлаулы, маҗаралы, фаҗигале язмышына юлыктык, «аһ» итеп, хәйран калып бу олы күңелле, корыч холыклы, мәгърур татар хатыны турында, әлбәттә, язарга, аның исемен татар халкына кайтарырга кирәк дигән карарга килгән идек.

Искә алынган китап юка тышлыклы, гадәти форматтан бераз зуррак кимәлдә, күләме 312 сәхифәдән гыйбарәт булган басмадыр [1]. Китап авторның төрек һәм татар телләрендә язылган кереш сүзе белән башлана. Моннан соң китапның эчтәлеге бирелә һәм Коньядагы Сәлҗүк университеты укытучысы, филология фәннәре кандидаты Алсу Шәмсутованың «Горурланыр елъязмалар» исемле кереш мәкаләсе белән дәвам ителә.

Китапның эчтәлеге дүрт бүлектән гыйбарәт. Беренче бүлек «Социаль барлык» дип атала. Биредә авторның 2017–2024 елларда төрле татар матбугат басмаларында чыккан татар-төрек халыкларының мөнәсәбәтләренә, аралашуларына кагылышлы хатирәви публицистик мәкаләләре урын ала. Бубыйлар нәселенең газиз парчасы булган Мәрьям ханым Атмаҗага багышланган мәкалә дә бу бүлектә урын ала. Йөрәкләрен майга төреп салмаганнарның күңелләрен елатырлык язмышлар кичкән бу ханымның тарихын биредә сөйләп тормыйм, чөнки бәяләмә язуымның максаты да Айзирәк ханымның китабына игътибарны җәлеп иттереп, укучыда аны үз кулларына алып укып чыгарга этәрүдер.

Икенче бүлек «Төрекчә китапларда, матбугатта татарлар язмышы» дип атала. Биредә урын алган язмалар аркылы автор татарларга карата игътибарның Төркиядә һичкайчан да сүнмәгәнлеген, тикшеренүчеләрне кызыксындыра торган, үзе турында яздыра торган мәүзугъ (тема) булып торганлыгын бәян итә.

Өченче бүлек «Сәяхәтнамәләр, эсселар» дип аталган. Биредә шулай ук автор ханымның әүвәлге елларда басылып чыккан мәкаләләре урын

ала, укучыны уртак татар-төрек мохитенә, ике тугандаш халыкның галәменә хыялый сәфәр шул рәвешле дәвамителә.

Дүртенче бүлек «Автор белән әңгәмәләрдән өзекләр» дип аталып, тирәнлеге һәм киңлеге белән дәрьяга тиң булган темага укучыны җитәкләп диярдәй озатуын дәвам итә, бу хакта уйлануларга, моңлануларга чумдыра. «*Ни кызганыч, Россиядән күченгән мөһатирләрнең балалары бакыйлыкка күчеп бара, ә мөһаҗир бабаларын, әбиләрен бала чакта күреп калган буын олыгаеп килә*», – дип яза Айзирәк ханым [1, б.285].

Дөрестән дә, татар халкының дөнья буйлап сибелгән асыл затлары бихисап. Үз илләрендә кадер-хөрмәт күреп бар көчләрен туган җирләренең үсешенә, алгарышына сарыф иткән булсалар иде, дөньялар да башкача булыр иде дә бит, язмыштан узмыш юк шул. Мәрхәмәтсез тарих туфаннары ул асыл кешеләрне генә түгел, алар турындагы хатирәләрне дә инде юкка чыгарып бара: нәсел дәвамчыларының хатирәләре, саргайган гәзит-журнал сәхифәләре – һәммәсе фани, һәммәсе акрынлап тарала бара, сүнә бара. Шуңа күрә ул таралган язмышларны, чәлпәрәмә килгән гүзәл өметләрнең калдыкларын бүген без күз яшьләрен түгә-түгә бөртекләп җыябыз, барлыйбыз, табышлар булса сөенәбез, тергезелүе мөмкин булмаган югалтуларга юлыксак көенәбез. Татар халкы тарихын аның вәкилләренең аянычлы тәкъдирләре аша язу эше шул рәвешле дә дәвам ителә. Айзирәк Гәрәева-Акчураның хезмәте дә бу эшнең кыйммәтле бер өлеше булып тора.

Якташыбыз Айзирәк бу юнәлештә эзләнүләрен дәвам итәр дип ышанасы килә, чөнки дөнья буйлап сибелгән татарларның Төркиядә төпләнеп калган вәкилләренә караган табышлар әле күп булачак.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Гәрәева-Акчура А. Төркиядә табылган татар эзләре: публицистик мәкаләләр, эсселар, тәрҗемәләр. Конья: «Atlas Akademi», 2024. 320 б.

**Автор турында белешмә:**

**Хәйретдин Айдар Гарифетдин улы** – фәлсәфи фәннәр кандидаты, доцент, ТР ФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институтының Я.Г. Абдуллин исемендәге диннәр һәм иҗтимагый фикер тарихы бүлеге мөдиренең урынбасары (Казан, Россия Федерациясе); ORCID: 0000-0003-0648-0466; e-mail: khaidar67@mail.ru

*Редакциягә керде 20.03.2025* *Кабул ителде 25.04.2025*

# Рецензия на книгу:
# Гараева-Акчура А. Татарские следы, обнаруженные в Турции: публицистические статьи, эссе, переводы (Конья, 2024)

***А.Г. Хайрутдинов***

*Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ*
*Казань, Российская Федерация*

Рецензия знакомит с содержанием и научной значимостью опубликованной в Турции книги, посвященной биографиям и общественной деятельности представителей татарской эмиграции, переселившихся в упомянутую страну в течение XX в. Ценность издания заключается в том, что автор дополняет новыми сведениями данные, относящиеся к судьбам татар, имена которых до сих пор остаются малоизвестными для татарской историографии. Кроме этого, автор презентует публикации о татарах в турецких периодических изданиях.

**Ключевые слова:** татары в Турции, татарская эмиграция, турецкая пресса о татарах, татарская публицистика, биографии

**Для цитирования:** Хәйретдинов А.Г. Китапка бәяләмә: Гәрәева-Акчура А. Төркиядә табылган татар эзләре: публицистик мәкаләләр, эсселар, тәрҗемәләр (Конья, 2024) [Рецензия на книгу: Гараева-Акчура А. Татарские следы, обнаруженные в Турции: публицистические статьи, эссе, переводы (Конья, 2024)] // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2025. Т.15, №2. С.145–149. https://doi.org/10.22378/2410-0765.2025-15-2.145-149

**Информация об авторе:**

**Хайрутдинов Айдар Гарифутдинович** – кандидат философских наук, доцент, и.о. заведующего отделом истории религий и общественной мысли им. Я.Г. Абдуллина, Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ (Казань, Российская Федерация); ORCID: 0000-0003-0648-0466; e-mail: khaidar67@mail.ru

*Поступила 20.03.2025* *Принята к публикации 25.04.2025*

# Book review: Garayeva-Akchura A. Tatar traces founded in Turkey: publicism articles, essays, translations (Konya, 2024)

***A.G. Khairutdinov***

*Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*

The review introduces the content and scientific significance of the book published in Turkey, dedicated to the biographies and social activities of representatives of the Tatar emigration who moved to the aforementioned country during the 20th century. The value of the publication lies in the fact that the author supplements the data related

to the fates of the Tatars, whose names still remain little known to Tatar historiography, with new information. In addition, the author presents publications about the Tatars in Turkish periodicals.

**Keywords:** Tatars in Turkey, Tatar emigration, Turkish press about Tatars, Tatar journalism, biographies

**For citation:** Khairutdinov A.G. Book review: Garayeva-Akchura A. Tatar traces founded in Turkey: publicism articles, essays, translations (Konya, 2024). *From History and Culture of Peoples of the Middle Volga Region.* 2025, vol.15, no.2, pp.145–149. https://doi.org/10.22378/2410-0765.2025-15-2.145-149 (In Tatar)

## REFERENCES

1. Garayeva-Akchura A. *Tatar traces founded in Turkey: publicism articles, essays, translations*. Konya: Atlas Akademi Publ., 2024. 320 p. (In Tatar)

**About the author:**
**Khairutdinov Aidar Garifutdinovich** – Cand. Sci. (philosophy), Associate Professor, Acting Head of the Abdullin Department of the History of Religions and Social Thought, Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (Kazan, Russian Federation); ORCID: 0000-0003-0648-0466; e-mail: khaidar67@mail.ru

*Received March 20, 2025* *Accepted for publication April 25, 2025*